РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

*Постановление* *Карар*

2022 елның 2 феврале Чистай шәһәре № *13*

Чистай шәһәре Башкарма комитеты карарларының
үз көчен югалтуын тану турында

Чистай шәһәр прокуратурасының муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру функцияләрен үтәүнең административ регламентына 2022 елның 25 гыйнварындагы 02-08-02-2022 номерлы протестын карап, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Чистай шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 25 гыйнварындагы 13 номерлы карары белән расланган «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын;
- Чистай шәһәре Башкарма комитетының «Чистай шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 25 гыйнварындагы 13 номерлы карары белән расланган «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль урман контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 18 декабрендәге 245 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ф.М. Садыйковка йөкләргә.

Чистай шәһәре
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Ф. Рәхимов